**СОВЕТ**
**Иж-Бобьинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Иж-Бубый авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2018 Иж-Бубый авылы № 39-1

Гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм куллану
мәсьәләсе буенча җирле референдум
билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 10, 11 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»2018 елның 28 августындагы 37-3 номерлы карары, Иж-Бубый авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 11 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылучылардан,  иректән мәхрүм ителгәннәрдән кала, Иж-Бубый авыл җирлегендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә территорияне төзекләндерү.

2. Зиратларны карап тоту.

3. Су белән тәэмин итү объектларын һәм су үткәргеч челтәрләрне карап тоту.

4. Авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту.

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны Иж-Бубый авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе Р.Р. ВАҺАПОВ